КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 11 март г.Казань № 200

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль кулланылыштагы торак фондының торак урыннарын наемгага алу шартнамәләре буенча торак урыннар алуга мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу тәртибен раслау турында» 2018 ел, 7 июнь, 432 нче карары белән расланган Социаль кулланылыштагы торак фондының торак урыннарын наемгага алу шартнамәләре буенча торак урыннар алуга мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль кулланылыштагы торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннар бирүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу тәртибен раслау турында» 2018 ел, 7 июнь, 432 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 4 апрель, 271 нче, 2020 ел, 24 февраль, 131 нче, 2020 ел, 29 сентябрь, 884 нче, 2021 ел, 22 сентябрь, 900 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Социаль кулланылыштагы торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннар бирүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу тәртибенә, 3.1 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«аларга дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген билгеләнгән тәртиптә торак йорт төзү өчен бирү, өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнардан, шулай ук федераль закон, Россия Федерациясе Президенты указы яисә Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән башка категориядәге гражданнардан тыш;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин